КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 10 февраль г.Казань № 128

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Граждан хәле актларын дәүләт теркәвенә алу өчен федераль вәкаләтләрне гамәлгә ашыру өчен федераль бюджеттан Татарстан Республикасы бюджетына бирелә торган субвенцияләрне тоту тәртибен раслау һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарлары үз көчен югалткан дип тану турында» 2019 ел, 18 октябрь, 933 нче карары белән расланган Граждан хәле актларын дәүләт теркәвенә алу өчен федераль вәкаләтләрне гамәлгә ашыру өчен федераль бюджеттан Татарстан Республикасы бюджетына бирелә торган субвенцияләрне тоту тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Граждан хәле актларын дәүләт теркәвенә алу өчен федераль вәкаләтләрне гамәлгә ашыру өчен федераль бюджеттан Татарстан Республикасы бюджетына бирелә торган субвенцияләрне тоту тәртибен раслау һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарлары үз көчен югалткан дип тану турында» 2019 ел, 18 октябрь, 933 нче карары белән расланган Граждан хәле актларын дәүләт теркәвенә алу өчен федераль вәкаләтләрне гамәлгә ашыру өчен федераль бюджеттан Татарстан Республикасы бюджетына бирелә торган субвенцияләрне тоту тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

6 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6. Субвенция исәбеннән граждан хәле актларын дәүләт теркәвенә алуга федераль вәкаләтләрне үтәүгә бәйле чыгымнар гамәлгә ашырыла.»;

7 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«7. Субвенцияләр түбәндәге чыгымнарны финанслауны тәэмин итүгә җибәрелә:

хезмәт өчен түләү һәм хезмәт өчен түләү буенча түләүләр;

командировка чыгымнары;

элемтә хезмәтләре;

транспорт хезмәтләре;

коммуналь хезмәт күрсәтүләр;

мөлкәттән файдалану хезмәтләре күрсәтү;

мөлкәтне карап тоту буенча эшләр, хезмәт күрсәтүләр;

башка эшләр, хезмәтләр;

төп чараларны алу;

матди запаслар алу;

салымнар, җыемнар һәм башка түләүләрне түләү;

башка чыгымнар.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин